**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 21 ноябрендәге 4101 номерлы карары**

**Казан шәһәре Идел буе районының Садовая урамында**
**ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарга 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитут характеристикасы:

- йогынты ясала торган өлкә мәйданы – 780 кв.м;
- хокуклар чикләнә торган кадастр кварталы – 16:50:170402;
- урнашу урыны: Казан шәһәре, Идел буе районы, Садовая урамы;
- билгеләү максаты: затларның чикләнмәгән даирәсенә элемтә хезмәтләре күрсәтү өчен кирәкле элемтә корылмасын эксплуатацияләү (антенналы-мачталы 16_340 номерлы элемтә корылмасы – биеклеге 45.0 м булган элемтә башнясы);
- билгеләү вакыты: 49 ел;

1.2. гариза бирүче: «БИК» ҖЧҖ;

1.3. билгеләү өчен нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.23, 39.37 статьялары, 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында»гы федераль законның 3.6 статьясы.

2. «Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарга 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

3. Сервитутны гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә кадастр кварталының бер өлешеннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яки сизелерлек кыенлашачак вакыт билгеләнмәгән.

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут өчен түләү Россия Федерациясе Җир кодексының 39.46 статьясындагы 2, 3, 4, 5, 7 һәм 8 пунктлар нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны, әлеге карарның 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.


7. «БИК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән кадастр кварталының бер өлешен, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яки агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү буенча эшләр тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктлар белән каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң өч айдан да соңга калмыйча, аңардан рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты рәисе Р.Г.Галәветдиновка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 21 ноябрендәге
4101 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

## Ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре




| Масштаб 1:500<br>Координаталар системасы: МСК-16 | |
|---|---|
| Шартлы билгеләр: | |
| 1 | Яңа ясалган характерлы нокта |
| | Ачык сервитутлар (Проектлана торган) |
| | Җир кишәрлекләре |
| 16:50:170402 | кадастр кварталы |

________________________________